Кызнын уяулыгы мошенниклар белән әнгәмәне озәргә һәм 1 млн сумлык кредит рәсмиләштерvгә юл куймаска ярдәм иткән.
Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск шәһәр округынын 3нче номерлы идарәсенен дежур олешенә 30 яшьлек жирле хатын-кыз морәжәгать иткән. Билгесез кешеләр әлеге кызга кредит рәсмиләштерергә тырышкан, дип хәбәр итә. Апрельнен сонгы коннәренен берсендә ана билгесез булган абонент номерыннан янәсе салым хезмәте вәкиленнән шалтырату килгән. Ул анын счетлары буенча шикле операцияләр узуын анлаткан: хәлләрне ачыклау очен әлеге шалтыратучы хезмәтнен кураторлык итvчесенә ашыгыч рәвештә кабул итvгә язылырга кинәш иткән. Монын очен анын vтенече буенча ул vзенә смс-хәбәрдә килгән кодны һәм ИНН номерын хәбәр иткән. Очрашу шул ук конне 15:00 сәгатьтә булырга тиеш булган. Берничә минуттан хатыннын почтасына хат килә: анда дәvләт хезмәтләрендә анын шәхси кабинетыннан документлар бушату турында хәбәр ителгән һәм ашыгыч рәвештә шалтыратырга кирәк булган телефон номеры кvрсәтелгән. Кызнын шәхси кабинетын ватканнар дип борчылып, бер дә уйлап тормыйча, кvрсәтелгән номер буенча шалтыраткан, ә анда анын исеменнән кредит рәсмиләштерv процессы турында хәбәр ителгән. Шуннан сон анын әнгәмәсе, янәсе (якобы), банк хезмәткәре белән дәвам иткән. Алдакчы, элемтә ли-ниясен биләмәс очен, әнгәмәне мессенджерда дәвам итәргә тәкъдим иткән. Анын сvзләренчә, билгесез кешеләр, кызнын документларыннан файдаланып, торле банкларга заемга гариза биргәннәр. Аларга акча бирелмәсен очен, алданрак эшләv һәм 1 млн сумлык кредит рәсмиләштерергә тиеш, дигән. Кыз, анын кvрсәтмәсе буенча консультатив ярдәм очен гариза язган, анда vзенен паспорт мәгълvматларын кvрсәткән. Аннары банкнын мобиль кушымтасына кvчеп, анда торле операцияләр ясауны дәвам иткән. Ниндидер мизгелдә ана барлык гамәлләр дә шикле булып тоелган һәм ул әнгәмәсен бvлеп, тиз генә МФЦга бара. Анда дәvләт хезмәтләре порталында vзенен шәхси кабинетында парольне vзгәртә. Нәтижәдә ул vзен 1 млн. сумлык кредиттан саклап кала алган.
Хәзерге вакытта оператив-эзләv комплексы vткәрелә. Жинаятьчеләрнен урнашу урынын билгеләvгә юнәлдерелгән чаралар башкарыла.